| ГЛАВНОЕ АРХИВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ПРИ КАБИНЕТЕ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН (ТАТГЛАВАРХИВ) | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ КАРШЫНДАГЫ БАШ АРХИВ ИДАРӘСЕ (ТАТБАШАРХИВ) |
|---|---|---|

БОЕРЫК

13.07.2015 Казан № 048

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән, б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең структур бүлекчәләре җитәкчеләре Тәртипнең һичшиксез үтәлешен тәэмин итәргә тиеш.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Д.И. Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
каршындагы Баш архив
идарәсенең
13.07.2015 № 048 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы
Баш архив идарәсенә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибе (алга таба – Тәртип) гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау эшен камилләштерү, аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын арттыру максатларында эшләнде.

1.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә (алга таба – Татбашархив) кергән мөрәҗәгатьләргә анализ уздыру Татбашархивка, Татарстан Республикасы дәүләт архивларына, «Гасырлар авазы – Эхо веков» фәнни-документаль журналы редакциясенә кергән барлык мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## II. Татбашархивка кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибе

2.1. Мөрәҗәгатьләргә анализ елына ике тапкыр уздырыла: ярты ел өчен һәм үтеп киткән ел өчен.

2.2. Татбашархивның структур бүлекчәләре, Татарстан Республикасы дәүләт архивлары җитәкчеләре, «Гасырлар авазы – Эхо веков» фәнни-документаль журналы редакциясе Татбашархив башлыгы урынбасарына агымдагы елда кергән мөрәҗәгатьләр турында, агымдагы елның 25 декабреннән дә соңга калмыйча, – мәгълүмати-аналитик һәм статистик материаллар, шулай ук агымдагы елның 25 июненнән дә соңга калмыйча, ярты еллык өчен хисаплар тапшыра.

2.3. Мөрәҗәгатьләргә анализ уздыру Татбашархив башлыгы урынбасары тарафыннан башкарыла.

2.4. Башлык урынбасары тапшырылган мәгълүмати-аналитик һәм статистик материалларны гомумиләштерү һәм анализ уздыру нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә төзи.

2.5. Аналитик белешмәдә кергән, башка адреска җибәрелгән һәм каралаган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгатьләр саны турында, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхсән кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны турында, гражданнарны шәхсән кабул итү

буенча вәкаләтле затлар һәм шәхсән кучмә кабул итү турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча күрелгән чаралар турында мәгълүмат, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм бүтән актлар (булса) турында мәгълүмат булырга тиеш.

2.6. Агымдагы елның 30 июненнән һәм 30 декабреннән дә соңга калмыйча, әлеге аналитик белешмә башлык урынбасары тарафыннан Татбашархив башлыгына карау өчен тапшырыла һәм Татбашархивның рәсми сайтында урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Милли архивының архив технологияләрен автоматлаштыру бүлегенә җибәрелә.

2.7.Татарстан Республикасы Милли архивының архив технологияләрен автоматлаштыру бүлеге белгечләре аналитик белешмәне алган көннән өч эш көне эчендә аналитик белешмәне Татбашархивның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтының www.arhiv.tatarstan.ru «Гражданнар мөрәҗәгатьләре» бүлегендә урнаштыра.

## III. Тәртип таләпләрен үтәмәгән өчен җаваплылык

3.1.Әлеге Тәртип таләпләрен үтәмәгән һәм гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру һәм халыкка җиткерү срокларын бозган очракта, вазыйфаи затлар законнарда билгеләнгәнчә җаваплы була.